# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

13 ноябрь 2024 ел.                                                                                    № 2

**2025 елда ТР Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең Урта Сон торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Сон авыл җирлегендә гражданнар җыены

Карар:

1«2025 елда үзара салым кертүгә Сез Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы  Сон авыл җирлеге Урта Сон  торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 һәм 2 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм (МХО) махсус хәрби хәрәкәтләрдә  катнашучыларның гаиләләреннән, тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнардан тыш, 700(Җиде йөз) сум күләмендә акча кертергә килешәсезме

2. Алынган акчаларны җибәрү.:

-Урта Сон торак пунктында Үзәк (Центральная) урамына юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, ком, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-Урта Сон т. п., Үзәк урамдагы спорт  мәйданчыгына бетон җәю;

-Урта Сон торак пунктында урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру;

- Урта Сон торак пунктында җирле әһәмияттәге юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту.

3. Җыенның әлеге карарын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. http://mamadysh.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында ( pravo.tatarstan.ru.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Мамадыш муниципаль районы
Сон авыл җирлеге башлыгы                                        М. Ф. Сәләхов